**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ГЛАВА УЛЬЯНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**УЛЬЯНОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

423115, Ульяновка село, Центральная ул., 44 дом тел./факс+7(84396) 2-33-16/2-33-17 email: Ul.Cmn2@tatar.ru 423115, Ульяновка авылы, Үзәк урамы, 44 йорт

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№ 3** **19 август 2024 ел**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ульяновка авыл җирлеге башлыгының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ульяновка авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 05 августындагы 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хәрби исәпкә алу турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2023 елның 25 июлендәге 1211 номерлы карары, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Ульяновка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ульяновка авыл җирлеге башлыгының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ульяновка авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 05 августындагы 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.2 нче пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: «3.2. Җирлектә гражданнарны яшәү урыны яисә булу урыны буенча (3 айдан артык вакытка) беренчел хәрби исәпкә алу, шул исәптән яшәү урыны һәм (яисә) булу урыны, яисә альтернатив граждан хезмәтен узу урыны буенча расланмаган теркәлү белән җирлекнең башкарма комитеты тарафыннан Россия Федерациясе законнары, Хәрби исәпкә алу турындагы нигезләмә һәм Россия Федерациясе оборона министрлыгы тарафыннан эшләнә торган методик тәкъдимнәр нигезендә гамәлгә ашырыла. Беренчел хәрби исәпкә алуның торышы өчен җирлекнең башкарма комитеты җитәкчесе җаваплы».

1.2. 3.7 пункны яңа редакциядә бәян итәргә: «3.7. Беренчел хәрби исәпкә алу документларындагы белешмәләргә үз вакытында үзгәрешләр кертергә һәм

10 эш көне эчендә кертелгән үзгәрешләр турында хәрби комиссариатка хәбәр итәргә».

1.3. 3.8 нче пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: «3.8. Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә хәрби исәптә тормаган, әмма торырга тиешле гражданнар турында белешмәләрне электрон формада тапшырырга».

1.4. Инструкциянең 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «Җирлектә гражданнарны яшәү урыны яисә булу урыны буенча (3 айдан артык вакытка) беренчел хәрби исәпкә алу, шул исәптән яшәү урыны һәм (яисә) булу урыны, яисә альтернатив граждан хезмәтен узу урыны буенча расланмаган теркәлү белән җирлекнең башкарма комитеты тарафыннан Россия Федерациясе законнары, Хәрби исәпкә алу турындагы нигезләмә һәм Россия Федерациясе оборона министрлыгы тарафыннан эшләнә торган методик тәкъдимнәр нигезендә гамәлгә ашырыла. Беренчел хәрби исәпкә алуның торышы өчен җирлекнең башкарма комитеты җитәкчесе җаваплы».

1.5. Инструкциянең 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «Хәрби билетларның (хәрби билетлар урынына бирелгән вакытлыча таныклыкларның), хәрби билетлар урынына белешмәләрнең яисә хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнар таныклыкларының, шул исәптән электрон документ рәвешендә, булу-булмавын һәм дөреслеген, шулай ук алардагы язмаларның дөреслеген, мобилизация күрсәтмәләренең булу-булмавын (хәрби билетларда яисә хәрби билетлар урынына белешмәләрдә аларны тапшыру турында тамгалар булганда), шәхси электрон карталар (хәрби исәпкә алу документларында аларны бирү турында тамгалар булганда), гражданнарны элеккеге яшәү урыны буенча хәрби исәптән төшерү турында хәрби исәпкә алу документларында тамгалар, Россия Федерациясе гражданнары паспортларында аларның хәрби бурычка мөнәсәбәте турында тамгалар, Россия Федерациясе Кораллы көчләренең шәхси номерлары белән жетоннар (хәрби бурычлылар өчен хәрби билетларда аларны тапшыру турында тамгалар булганда) тикшерә».

1.6 Инструкциянең 5 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «запастагы офицерларга беренчел исәп карточкаларын тутыралар. Прапорщиклар, мичманнар, старшиналар, сержантлар, солдатлар һәм запастагы матросларга алфавит һәм исәп карточкаларын (2 нөсхәдә) тутыралар. Призывникларны беренчел хәрби исәпкә алу карталарын тутыралар. Күрсәтелгән документлар хәрби билетлардагы (хәрби билетлар урынына бирелгән вакытлыча таныклыкларда), хәрби билетлар урынына белешмәләрдә һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнар таныклыкларындагы язмалар нигезендә, шул исәптән электрон документ рәвешендә тутырыла. Бу чакта гражданнарның гаилә хәле, белеме, эш (уку) урыны, вазыйфасы, яшәү урыны яисә булу урыны турында, шул исәптән яшәү урыны һәм (яисә) булу урыны буенча теркәлү белән расланмаган белешмәләр һәм хәрби исәпкә алына торган гражданнарның документларындагы башка кирәкле белешмәләр төгәлләштерелә»;

1.7. Инструкциянең 10 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә хәрби исәптә тормаган, әмма торырга тиешле гражданнар турында белешмәләрне электрон рәвештә тапшырырга».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районының
Ульяновка авыл җирлеге башлыгы С.З. Шәмсетдинов